**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 март № 143

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче; 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы; 2011 ел, 29 июль, 609 нчы; 2011 ел, 7 сентябрь, 747 нче; 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы; 2012 ел, 30 июнь, 567 нче; 2012 ел, 30 июль, 645 нче; 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче; 2013 ел, 19 март, 186 нчы; 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче; 2014 ел, 20 май, 332 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1939 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 нче пунктта:

3.2.1 нче пунктчаның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвестицион эшчәнлекне дәүләт тарафыннан җайга салу (01.10 <*>);»;

3.2.10 нчы пунктчага «файдалану»)» сүзләреннән соң «, төрле диннәрдәге дини берләшмәләр арасында үзара аңлашуны һәм түземлелекне ныгытуда булышлык күрсәтү» сүзләрен өстәргә;

3.2.11 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.11. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе белән үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге функциясен гамәлгә ашырганда (03.02.05 <*>);»;

3.2.14 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.14. Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигать ресурсларыннан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06 <*>);»;

3.2.15 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.15. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән торак, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү базарларын формалаштыру өчен шартлар тудыру функциясен гамәлгә ашырганда (04.01.01 <*>).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\143.doc